СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

11.12.2024 № 52/3
На №__________ от______________

**Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, муниципаль район уставының 94, 95 статьялары нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 14/5 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 6 статьяның 1 өлеше 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13) әйләнә-тирә мохитне саклау буенча җирлекара характердагы чаралар оештыру, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә тиешле муниципаль район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм үткәрү;»;

2) 6 статьяның 1 өлеше 28 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28) җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

3) 6 статьяның 1 өлеше 33 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«33) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм тормышка ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

4) 6 статьяның 1 өлеше 34 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«34) Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итүне дә кертеп, шулай ук су объектларыннан рекреация максатларында файдалану кагыйдәләрен билгеләү;»;

5) 6 статьяның 1 өлеше 40 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«40) федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау;»;

6) 6 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 42 пунктны өстәргә:

«42) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыру һәм муниципаль район милкендә булган җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата мондый зыянны бетерүне оештыру.»;

7) 6 статьяның 2 өлеше 15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15) җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

8) 6 статьяның 2 өлеше 23 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23) федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруда катнашу;»;

9) 8 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирле үзидарә органнары аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен, муниципаль берәмлекләргә бу максатларга бүлеп бирелгән матди ресурслар һәм финанс чаралары чикләрендә җаваплылыкка ия.»

8 статьяның икенче абзацы 2025 елның 1 гыйнвареннан үз көченә керә;

10) 26 статьяның 11 өлеше 2 пункты «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел һөнәри берлек оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциясендә) якиә гомуми җыелышында катнашу;»;

11) 26 статьяның 11 өлеше 2 пункты «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) алдан хәбәр итеп, коммерциясез оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел һөнәри берлек оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашудан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашудан тыш);»;

12) 29 статьяның 1 өлеше 28 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яки) челтәр басмасын булдыру;»;

13) 44 статьяның 1 өлеше 3 пункты унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

14) 44 статьяның 1 өлеше 3 пункты унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итүне дә кертеп, шулай ук су объектларыннан рекреация максатларында файдалану кагыйдәләрен билгеләү;»;

15) 44 статьяның 1 өлеше 3 пункты megan undүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау;»;

16) 44 статьяның 1 өлеше 6 пункты дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм тормышка ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

17) 44 статьяның 1 өлеше 9 пункты унҗиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»

18) 44 статьяның 1 өлеше 9 пункты егерме бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау;»;

19) 57 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«57 статья. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат, муниципаль хезмәткәр

1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар булып депутат, җирле үзидарәнең даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булган сайланулы органының хәлиткеч тавыш хокукына ия, комиссиядә даими (штат) нигездә эшләүче әгъзасы тора. Муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе, муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы урынбасары, муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы аудиторы вазыйфалары.

2. Муниципаль хезмәткәр булып федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә җирлек бюджеты акчалары хисабына түләнә торган акчалата түләү өчен муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча бурычларны үтәүче граждан тора.

3. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник тәэмин итү вазыйфаларын башкаручы затлар муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләмиләр һәм муниципаль хезмәткәрләр булып тормыйлар.»;

20) 58 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 13 пунктны өстәргә:

«13) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә турында» 2007 елның 2 мартындагы Федераль законның $15^{2}$ статьясында каралган анкетадагы белешмәләргә аңа билгеле булган үзгәрешләр турында эшкә алучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәреш кергән белешмәләрдән тыш (алга таба – анкетадагы белешмәләр).»;

21) XI - XVI бүлекләрне X - XV бүлекләр дип санарга.

22) 79 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «79 статья. Муниципаль норматив хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибе»

«1. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы Тукай муниципаль районы булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү булып тора:

1) тулы текстны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәү турында таныклык ЭЛ № ФС 77-60244, Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 17.12.2014 бирелгән) яки «Якты юл» («Светлый путь») район газетасында (теркәү турында таныклык ПИ № ФС-4769) рәсми бастырып чыгару.

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районы сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) урнаштыру.

3. Гражданнарның Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында түбәндәге адрес буенча урнашкан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пункты эшли: ТР, Яр Чаллы ш., Муса Җәлил проспекты, 46 й.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр аларга кул куелган көннән алып 10 көн эчендә халыкка җиткерелә, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яки аларның аерым нигезләмәләреннән тыш.

5. Тукай муниципаль районы Советының салымнар һәм җыемнар турында норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза куелган көннән үз көченә керә.

7. Муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка җиткерү (рәсми бастырып чыгарудан тыш) вакытлы матбугат басмаларының, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның домен исемнәрен һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турында белешмәләрне күрсәтеп, челтәр басмаларының исемлеге район Башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән җәмәгатьчелеккә җиткерелә.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Якты юл» («Светлый путь») газетасында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында http:tukay.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар дәүләт теркәвеннән соң рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары — Р.И. Закиров

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2024 елның 23 декаберендә теркәлгән № 165390002024002.